Өченче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль район Советының егерме алтынчы утырышы

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

25 июль, 2019 ел № 208

Питрәч муниципаль районында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү турында

«Питрәч муниципаль районында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары докладын тыңлаганнан соң, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районында һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итү турында докладны игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы мәгариф бүлегенә тәкъдим итәргә:

2.1. аерым контрольдә тоту:

- чират таләпләрен үтәү, шулай ук балаларны мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренә кабул итү тәртибен;
- муниципаль мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләрендә һәр бала өчен күрсәтелә торган белем бирү хезмәтләренең һәркем өчен мөмкин булуын тәэмин итүен;
- сәламәтлек саклау органнары белән берлектә балаларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту буенча чаралар үткәрүен;

2.2. иҗтимагый оешмалар вәкилләрен һәм депутатлар корпусын һәркем өчен мөмкин булган һәм түләүсез мәктәпкәчә белем алуга хокукларны гамәлгә ашыруның дәүләт гарантияләрен тәэмин итүне тикшереп тору чараларына җәлеп итәргә.

3. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Питрәч муниципаль районы Советының социаль мәсьәләләр, сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният һәм яшьләр эшләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И. М. Кашапов